**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы,423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2021 елның «15» мартыннан № 120

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның шәхси милегендәге җирләргә керми торган яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау хакында

Россия Федерациясе Урман кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендәге Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның хосусый милкендәге җирләргә керми торган яшел үсентеләрне рациональ файдалану, саклау һәм яңадан җитештерү максатларында, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. Кушымта итеп бирелгән Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендәге Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы Нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль

районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасарына йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фәсахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2021 елның «15» мартындагы №
120 карары белән расланган

Татарстан Республикасының Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә Россия Федерациясе дәүләт урман фонды җирләренә һәм физик һәм юридик затларның шәхси милкендәге җирләргә кермәгән яшел үсентеләрне кисү тәртибе турында
Нигезләмә

## 1. Төп төшенчәләр

Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

Яшел үсентеләр - табигый һәм ясалма үстерелгән агач, куак һәм үлән булып үсә торган үсемлек (шул исәптән парклар, скверлар, бакчалар, газоннар, чәчәклекләр, шулай ук аерым торучы агачлар һәм куаклар).

Табигый территорияләр - хуҗалык эшчәнлеге кагылмаган яисә аз кагылган бердәм географик (климатик) шартларда формалашкан, җир рельефының, туфракның, үсемлекләрнең билгеле бер төрләрен үз эченә алган территорияләр.

Яшелләндерелгән территорияләр - табигый барлыкка килгән үсемлекләр участоклары, ясалма яшелләндерү объектлары (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш), төрле функциональ билгеләнештәге җирләрнең 50 процентган да ким булмаган өлеше үсемлекләр белән капланган аз төзелешле участоклары.

Урман территорияләре - төрле функциональ билгеләнештәге, табигый барлыкка килгән урман үсемлекләре белән капланган табигый территорияләр участоклары.

Агач - 5 см.дан ким булмаган диаметрлы төгәл кәүсәле, үсентеләрдән тыш,1,3 м биеклектәге үсемлек.

Куак - туфрак өслеге янында ук ботаклана торган күпьеллык (агачтан аермалы буларак) үсемлек.

Үлән капламы -газон, табигый үләнлек.

Куаклык - нинди дә булса урында куе булып үсә торган үсемлекләр, куаклар.

Яшел массив - бердәм яшеллек барлыкка китерүче 50 данәдән дә ким булмаган (15 яшьтән өлкәнрәк) агач үсә торган территория участогы.

Яшел үсентеләргә зыян китерү - яшел үсентеләргә аларның үсешен туктатуга китермәгән зыян китерү, , шул исәптән ботакларга, тамыр системасына механик зыян китерү, кайрының бөтенлеген, тере туфрак катламын бозу, яшел үсентеләрне яисә тамыр зонасындагы туфракны зарарлы матдәләр белән пычрату, ут төртү яки башка йогынты ясау.

Яшел үсентеләрне юк итү - яшел үсентеләрне кисү яки башка зыян китерү, аларның үсешен туктату.

Компенсацион яшелләндерү - 2 коэффициент белән зарарланган яки юк ителгән яшел үсентеләрне яңадан утырту.

## 2. Яшел үсентеләрне саклауның төп принциплары

Муниципаль берәмлек территориясендә үсә торган яшел үсентеләр саклагыч, рекреацион, эстетик функцияләрне башкара һәм сакланырга тиеш.

2.1. Муниципаль берәмлек территориясендә (авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләрдән тыш) урнашкан барлык яшел үсентеләр (агачлар, куаклар) сакланырга тиеш.

2.2. Муниципаль берәмлек территориясендә яшел үсентеләрнең сакланышын һәм үсешен тәэмин итү бурычлары йөкләнә:

2.2.1. оешмаларга үзләре башкарган эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыру өчен бирелгән участокларда - әлеге оешмалар җитәкчеләренә;

2.2.2. милектәге яки арендага алынган участокларда - юридик затларга һәм милекче гражданнарга яки арендаторларга.

2.3. Яшел үсентеләр урнашкан җир кишәрлекләренең милекчеләре, кулланучылары һәм арендаторлары яшел утыртмаларның сакланышын тәэмин итәргә, яшел үсентеләрне тиешенчә карарга тиешләр.

2.4. Әлеге Нигезләмә, милек рәвешләренә бәйсез рәвештә, муниципаль берәмлек территориясендә агач-куак кисүгә бәйле проектлау, төзелеш, ремонт һәм башка эшләр алып баручы барлык оешмаларга һәм гражданнарга кагыла.

2.5. Авыл җирлеге территориясендә хуҗалык, шәһәр төзелеше һәм башка эшчәнлек Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнары һәм әлеге Нигезләмә белән билгеләнгән яшел үсентеләрне саклау таләпләрен үтәп башкарыла.

2.6. Төзелеш, хуҗалык һәм башка эшчәнлекне оештыруга проект алды һәм проект документларында яшел үсентеләрнең торышы турында тулы һәм дөрес белешмәләр һәм проектлана торган объектның яшел үсентеләргә йогынтысын тулы бәяләү булырга тиеш.

2.7. Яшел үсентеләр яшәешен тәэмин итү белән ярашмый торган максатларда яшел территорияләрне һәм яшел массивларны куллану рөхсәт ителми.

## 3. Яшел үсентеләрне (агачлар, куакларны) кисү тәртибе)

3.1. Муниципаль берәмлек территориясендә яшел үсентеләрне үз белдегең белән кисү тыела.

3.2. Муниципаль берәмлек территориясендә агач һәм куакларны кисү рөхсәт нигезендә башкарыла. Кисүгә рөхсәт Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе күрсәтмәсе рәвешендә рәсмиләштерелә.

3.3. Яшел үсентеләр кисүгә рөхсәт алу өчен мөрәҗәгать итүче Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе исеменә гариза бирә (1 нче кушымта), анда үсентеләрнең саны, атамасы,

аларның торышы, чикләнгән кисү урыны һәм аны нигезләү күрсәтелергә тиеш. Гаризага түбәндәге документлар теркәп бирелә:

3.3.1. Шәхесне раслаучы документлар;

3.3.2. Вәкилнең вәкаләтләрен раслаучы документ (әгәр мөрәҗәгать итүче исеменнән вәкил эш итсә);

3.3.3. Кисәргә тиешле яшел үсентеләрне төшерү белән якындагы корылмаларга яки башка юнәлешләргә кадәр җир кишәрлеге схемасы;

3.3.4. Җир кишәрлеге Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында теркәлмәгән булса, җир кишәрлегенә хокук билгели торган һәм хокук раслый торган документларның расланган күчермәләре;

3.3.5. Биналар һәм корылмалар төзегәндә габаритларга туры килә торган яшел үсентеләр киселгән очракта, расланган проект документлары;

3.3.6. Яшел үсентеләрне кисү һәм утырту шартларын территория хуҗалары белән килештерү;

3.3.7. Үсентеләрне утыртканда яки күчереп утыртканда инженер челтәрләре вәкилләре белән җир эшләрен башкаруга ордер ачу белән килешү.

3.4. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Б ашкарма комитеты гариза-хат килгәннән соң, гариза бирүчегә әлеге төр эшләрне башкаруга рөхсәт алган махсус оешмага түбәндәгеләрне алу өчен мөрәҗәгать итәргә киңәш итә:

3.4.1. яшел утыртмаларның исәп-хисап исемлеге;

3.4.2. киселегрә тиешле агач утыртмаларының санын, төрен, категориясен билгеләү максатларында төзелә торган яшел үсентеләрне натураль техник тикшерү акты;

3.4.3. киселгән агач өчен түләүне (түләү) исәпләү. Киселгән агач өчен түләү Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 22.05.2007 ел, №310 карары белән расланган ставкалар нигезендә аерым исәпләнә.

Югарыда күрсәтелгән эшләрне башкару гариза бирүче хисабына башкарыла.

Рөхсәтнең гамәлдә булу срогы - 90 көн.

3.5. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районыБбашкарма комитеты мөрәҗәгать итүченең хат-гаризасы, яшел үсентеләрне техник тикшерү акты, киселгән агач өчен бәяне (түләү) исәпләү хисабы нигезендә муниципаль берәмлек территориясендә яшел үсентеләр кисүгә рөхсәт турында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты боерыгы проектын әзерли.

3.6. Эшләр башкаруга рөхсәт алган очракта, мөрәҗәгать итүче әлеге Нигезләмә нигезендә яшел үсентеләр кискән өчен түләүләрне кертергә һәм компенсацион яшелләндерү тәртибен раслаучы документларны тапшырырга тиеш.

3.7. Агач һәм куак кискән өчен түләү гариза бирүче тарафыннан муниципаль берәмлек бюджетына күчерелә.

3.8. Яшел үсентеләрне кисү эшләре билгеләнгән нормаларга һәм кагыйдәләргә туры китереп, гариза бирүче акчасы хисабына башкарыла. Агач кисү бары тик аттестацияләнгән белгечләргә генә рөхсәт ителә.

3.9. Киселгән яшел үсентеләрне һәм киселгән калдыкларны егу, кисү, төяү һәм чыгару эшләре гариза бирүче хисабына эш башланган көннән өч көн

эчендә башкарыла. Киселгән яшел үсентеләрне һәм киселгән калдыкларны эш урынында саклау тыела.

3.10. Киселгән урынга якын территориядә газон, яшел үсентеләр зыян күргән очракта, эш башкаручы аларны территория хуҗасы һәм аларның компетенциясе чикләрендә контрольлек итүче органнар белән килештерелгән срокларда, ләкин зыян килгән мизгелдән ярты елдан да соңга калмыйча, мәҗбүри рәвештә торгызу эшләрен башкара.

3.11. Агач кискән өчен түләүне башкармыйча гына, агач һәм куакларны кисү Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан түбәндәге очракларда рөхсәт ителергә мөмкин:

3.11.1. чистарту өчен кисү, санитар кисүләр һәм яшел үсентеләрне реконструкцияләгәндә;

3.11.2. авария һәм башка гадәттән тыш хәлләрне бетерү, шул исәптән җир асты коммуникацияләрен һәм капиталь инженерлык корылмаларын ремонтлау;

3.11.3. әгәр дәүләт санэпидемнадзор бәяләмәсе булса, торак һәм җәмәгать биналарында ут режимын бозучы агач һәм куакларны кисү;

3.11.4.авария куркынычы тудыра торган (аву мөмкинлеге булган, корысары) агачлар һәм куакларны кисү.

3.12. Югарыда күрсәтелгән очракларда яшел үсентеләр кисүне гамәлгә ашыручы мөрәҗәгать итүчегә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты белән килештерелгән урыннарда компенсацион яшелләндерүне үткәрергә кирәк.

3.13. комиссия тикшерүе нигезендә 2 нче кушымтада бирелгән акт нигезендә авария, коры-сары һәм куркынычсызлык тудыручы яшел үсентеләр киселә.

3.14. РФ Урман кодексының 20 статьясы нигезендә, хуҗалык эшчәнлеге нәтиҗәсендә яки җир кишәрлегендә аны гражданга яки юридик затка милеккә тапшырганнан соң барлыкка килгән агач-куак үсемлекләре аның милке булып тора, ул алардан үз теләге белән файдалана һәм эш итә.

3.15. Яшел үсентеләрне санкциясез кисү яки юк итү дип түбәндәгеләр танылa:

3.15.1. рөхсәтсез яки рөхсәт белән, әмма рөхсәттә күрсәтелгән участокта түгел, тиешле санда һәм төрләр булмаган агач һәм куакларны кисү

3.15.2. ут төртү яки ут белән саксыз эш итү нәтиҗәсендә агач һәм куакларны юк итү яки зыян китерү;

3.15.3. кәүсәне бoҗралату яки кыскарту;

3.15.4. үсә трган агачлар һәм куакларга үсеш дәрәҗәсе тукталганга кадәр зыян итү;

3.15.5. агач һәм куакларга агынты сулар, химик матдәләр, калдыклар белән һ. б. шундый зыян китерү;

3.15.6. үз белдегең белән корыган агачларны кисү;

3.15.7. үсүче агачлар һәм куакларны башкача җәрәхәтләү.

3.16. Дәүләт урман фондында булган агач һәм куакларны кисү махсус вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан бирелгән рөхсәтләр нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.17. Әлеге Нигезләмәне бозып агач һәм куакларны юкка чыгару үз белдеге белән киселгән дип санала һәм Россия Федерациясе һәм Татарстан

Республикасы законнары нигезендә административ һәм җинаять җаваплылыгына тартылырга тиеш. Әлеге Нигезләмә кагыйдәләрен үтәү муниципаль берәмлек территориясендәге барлык гражданнар, оешмалар һәм учреждениеләр өчен мәҗбүри.

## 4. Компенсацион яшелләндерү

4.1. Компенсацион яшелләндерү рөхсәт ителгән агач кисү, законсыз рәвештә яшел үсентеләрне зарарлау яки юк итү очракларында гамәлгә ашырыла. Компенсацион яшелләндерү агачлар, куаклар һәм газоннар утырту өчен туры килә торган сезонда, әмма яшел үсентеләрне зарарлау яки юк итү факты ачыкланганнан соң бер елдан да соңга калмыйча башкарыла.

4.2. Компенсацион яшелләндерү гражданнар яисә юридик затлар акчалары хисабына , аларның мәнфәгатьләрендә яки аларның хокукка каршы гамәлләре нәтиҗәсендә яшел утыртмаларга зыян килгән яки юк ителгән очракта башкарыла

4.3. Әлеге Нигезләмә нигезендә, яшел үсентеләргә китерелгән зыян натураль рәвештә кайтарылырга тиеш-компенсацион яшелләндерү: 2 коэффициенты белән юкка чыгарылган яшел үсентеләрне яңадан торгызу.

## 5. Шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашырганда яшел үсентеләрне саклау

5.1. Муниципаль берәмлектә шәһәр төзелеше эшчәнлеген гамәлгә ашыру яшел үсентеләрне саклау таләпләрен үтәү белән алып барыла.

5.2. Яшелләндерелгән территорияләр, шул исәптән яшел массивлар, шулай ук яшелләндерелгән территорияләрне үстерү өчен билгеләнгән җир кишәрлекләре төзелеш өчен һәм аларның максатчан билгеләнешенә бәйле булмаган максатларда кулланылырга тиеш түгел.

5.3. Яшел үсентеләр биләгән җир кишәрлекләрендә төзелешне оештырганда, проект алды документларында киселергә тиешле яшел үсентеләрне бәяләү булырга тиеш. Бу очракларда зыянны каплау әлеге Нигезләмәнең 2 һәм 3 бүлекләрендә билгеләнгән тәртиптә агач киселгән өчен түләүне алдан кертү һәм компенсацион яшелләндерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

## 6. Эшмәкәрлек эшчәнлеген тормышка ашырганда яшел үсентеләрне саклау

6.1. Яшелләндерелгән территорияләрдә һәм яшел массивларда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты рөхсәтеннән башка сәүдә һәм башка эшмәкәрлек эшчәнлеге, палаткалар һәм башка корылмалар урнаштыру тыела.

6.2. Яшел территорияләрдә һәм яшел массивларда эшмәкәрлек эшчәнлеген тормышка ашырганда шартлаткыч, утлы һәм агулы матдәләр куллану, территорияне пычрату һәм чүпләү, яшел үсентеләргә зыян китерергә яки юк итәргә сәләтле башка гамәлләр тыела.

## 7. Административ җаваплылык

7.1. Әлеге Нигезләмәне бозуда гаепле затлар Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплы.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә РФ дәүләт урман фонды җирләренә керми торган яшел үсентеләрне кисү тәртибе турындагы Нигезләмәгә 1 нче номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенә

_____________________________________

____________________________________

______________________________________

______________________________________

(оешманың исемен күрсәтергә яки Ф. И. О., адрес)

ГАРИЗА
ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТЕРРИТОРИЯСЕНДӘ
АГАЧ-КУАК ҮСЕМЛЕКЛӘРЕН
ЧИКЛӘНГӘН КИСҮГӘ

Түбәндәге җир кишәрлегендә үсүче агач, куак, агач-куак үсентеләрен (тиешлесен ассызыкларга) кисүне рөхсәт итүегезне сорыйм

_________________________________________________________________________

_________________________________________________________________________

(оешманың исемен яки Ф. И.О. һәм җир кишәрлегенә хокук төрен күрсәтергә)
_____________________________________________җирдә урнашкан
(торак пунктны күрсәтергә)
Җир кишәрлегендә:
агачлар ______________________________ төп,
куаклар ______________________________ төп.
Җир кишәрлеген үзләштерү һәм төзекләндерү барышында агач кискән өчен түләү кертергә һәм агач-куак үсентеләрен компенсацияләп утыртырга йөкләмә алам.

_______________ ________________
Ф. И. О. (Имза)
Дата _____________

Кушымталар:
1. Беренчел - рөхсәт документлары.
2. Кисү күздә тотыла торган яшел үсентеләрнең төре һәм санын төшереп, җир участогы планы.

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә РФ дәүләт урман фонды җирләренә керми торган яшел үсентеләр кисү тәртибе турындагы Нигезләмәгә 2 нче кушымта

# АКТ

## ЯШЕЛ ҮСЕНТЕЛӘРНЕ КИСЕЛЕРГӘ ТИЕШЛЕ ДИП ТАНУ ТУРЫНДА

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты

«_____»__________ _________ ел

Комиссия составы:

1.______________________________________________________________

(Ф.И.О., вазыйфасы)

2.______________________________________________________________

(Ф.И.О., вазыйфасы)

3.______________________________________________________________

(Ф.И.О., вазыйфасы)

яшел үсентеләр тикшерелде.

Тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәгеләр билгеле булды:

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Нәтиҗәләр:

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

______________________________________________________________________

Комиссия әгъзалары:

1. _________________________ ________________________
   (имза) (Ф.И.О.)
2. _________________________ ________________________
   (имза) (Ф.И.О.)
3. _________________________ ________________________
   (имза) (Ф.И.О.)